ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«08 ноябрь 2021 ел** **№ 1188**

**2022 елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын Арча муниципаль районы балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларын раслау турында**

1. 2022 елга түбәндәгеләрне расларга (кушымта итеп бирелә):

2022 елга Арча муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларын;

2022 елга Арча муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларын исәпләү тәртибе турында Нигезләмәне.

2. “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы финанс-бюджет палатасы” муниципаль казна учреждениесенә:

гомуми белем бирү оешмаларын әлеге карарның 1 пунктында расланган гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары нигезендә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм “Интернет” челтәрендә Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk/tatarstan.ru) халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р.Мөхәрәмов

Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
08.11. 2021 ел, №1188
карары белән расланды

2021 елга Арча муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары

1.

| Автотранспорт чарасы моделенең атамасы | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасы ставкасы, елга сум | автотранспорт чарасының бер километр юл узуга ставкасы, сум |
| КАВЗ | 77076 | 38,77 |
| ПАЗ | 76795,5 | 38,68 |
| ГАЗ «Газель» | 66621 | 31,16 |
| УАЗ | 66394,5 | 29,69 |
| FIAT | 68315 | 28,02 |
| Peugeot Boxer | 71031,5 | 27,66 |
| Ford Transit | 71160 | 31,34 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 78031,5 | 36,63 |

Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
08.11.2021 ел, № 1188 карары
белән расланган

Арча муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары исәпләү тәртибе турында Нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Арча муниципаль районы балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү (алга таба – муниципаль хезмәт) бәясен исәпләү механизмын билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм автотранспорт чараларының хисап чорында факттагы үткән юлы нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары ел саен Арча муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының фактта узган юлы турындагы мәгълүмат автотранспорт чарасының расланган паспорты кысаларында эшләнгән Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча кабул ителә.

2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1. I- муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

биредә:

$S_i$ -муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

$n_{f\,m}$ - m модельле автотранспорт чараларының фактта узган юлы;

$NF_{km_m}$ - балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру бәясе нормативының бер километрга ставкасы, сум;

$NF_{as\,m}$ - гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыруның бер автотранспорт чарасына бәясе нормативы ставкасы;

$M_m$ - m модельле автотранспорт чаралары саны, берәмлек;

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделе исеме;

$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус модельләре саны